К А Р А Р

П О С Т А Н О В Л Е Н И Е №5

2019 елның 21 гыйнвары

“Лениногорск муниципаль районы” Башлыгы, Лениногорск шәһәре мэрының 2015 елның 23 мартында 81нче номер белән кабул ителгән “Торак төзелеше өлкәсендәге процедураларның тулы исемлеге турындагы» карары белән расланган торак төзелеше өлкәсендәге процедураларның тулы исемлегенә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2014 елның 30 апрелендәге 403нче номерлы (21.04.2018 ред.) “Торак төзелеше өлкәсендәге процедураларның тулы исемлеге турындагы» карарына (торак төзелеше өлкәсендәге процедураларның тулы исмелегенә үзгәрешләр кертү кагыйдәләре, торак төзелеше өлкәсендәге процедураларның тулы исемлегендә күрсәтелгән процедураларның бәяләмәсе реестрын алып буры Кагыйдәләре белән берлектә) туры китерелеп, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 6нчы статьясы, 2нче часте буенча, “Лениногорск муниципаль район” муниципаль районы Уставы нигезендә, КАРАР БИРӘМ:

1.“Лениногорск муниципаль районы” Башлыгы, Лениногорск шәһәре мэрының 2015 елның 23 мартында 81нче номер белән кабул ителгән “Торак төзелеше өлкәсендәге процедураларның тулы исемлеге турындагы» карары белән расланган торак төзелеше өлкәсендәге процедураларның тулы исемлегенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1нче бүлектә:

пункт 1.1 не көчен югалткан дип санарга;

пункт 1.2 не түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.2. Дәүләт һәм муниципаль милектә булган җир участогына хокукны сату буенча арендалау өчен килешү төзү өчен аукцион оештыру һәм үткәрү”;

пункт 1.7 не көчен югалткан дип санарга;

пункт 1.8 не түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.8. Төзелгән территорияне үстерү өчен килешү төзү хокукы буенча аукцион оештыру һәм үткәрү”;

пункт 1.12 не көчен югалткан дип санарга ;

пункт 1.13не түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.13. Дәүләт һәм муниципаль милектә булган җир участогына, яисә торак төзелеше өчен дәүләт һәм муниципаль милектә булган җир участогына аренда килешүе өчен хокук аукцион оештыру һәм үткәрү»

2нче бүлектә:

Түбәндәге эчтәлектәге 2.4, 2.5, 2.6 пунктлар белән тулыландырырга:

«2.4.Капиталь төзелеш объектында эшләр башлану турында хәбәр җибәрү.

2.5. Тикшерелергә тиешле объектларда эш төгәлләнү сроклары турында хәбәр җибәрү.

2.6.Кимчелекләрне төзәтү турында хәбәр җибәрү.”;

3нче бүлектә:

Түбәндәге эчтәлектәге 3.2. пункты белән тулыландырырга:

«3.2 Капиталь төзелеш объектына адрес бирергә.».

2. Әлеге карарны рәсми-публикатор «Лениногорские вести» газетында һәм Лениногорск муниципаль районының рәсми интернет-сайтында һәм хокукый мәгълүмат порталында урнаштырырга.

3.Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны “Лениногорск муниципаль районы” муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты җитәкчесе Н.Р. Залаковка йөкләргә.

Р.Г. Хөсәенов

И.Р. Хәйбрахманов
5-44-72